**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән олимпиада биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ**
**2025-2026 нчы уку елы**
**11 нче сыйныф**

**Максималь балл – 67**

## I. ТЕСТ (20 балл)

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **2** | **2** | **1** | **2** | **4** | **1** | **3** | **2** | авырлыклар | максат хәле |

## II. Теоретик бирем.

Тезмә кушма җөмлә турында языгыз, мисаллар китерегез. **(8 балл)**

Укучы мәктәп программасы, дәреслекләрдә бирелгән материалны мөмкин кадәр тулы чагылдырган очракта, мисаллар белән дәлилләгәндә, биремгә иң югары балл куела. Төгәлсезлекләрнең күләменә карап, баллар саны киметелә. Мәгълүмат бөтенләй булмаган очракта, укучыга 0 балл куела.

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Фразеологизмнар һәм аларның мәгънәләре арасында тәңгәллек урнаштырыгыз, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) ата йорты | 1) ял итеп алу |
| Ә) бәлеш авыз | 2) үч саклау |
| Б) баш кую | 3) хәтере тиз калучан кеше |
| В) үпкә бәлеше | 4) елак бала |
| Г) кинә тоту | 5) ватан |

**Җавап: 54132**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Бирелгән сүзләрнең тамырын билгеләп языгыз. **(5 балл)**

Безелдәвек – **без**
Тузганак – **туз(у)**
Киселмәле – **кис(ү)**
Кадак – **када(у)**
Аңлаешсызлык – **аң**

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(1 балл) һәр хәрефкә 0,5 балл**

«Сул аягың җиргә ныклап терә,
Чыбыркыңны уң кулыңа, ипләп…»
Көтүлектә шартлый кыюсыз чаң,
Г**а**ләм хәтеренә аваз киртләп.
Тагын, тагын… Елан төсл**е** ыслап,
Чыелдатып шартлый чыбыркым ла.
Мин җәйләүдә. Мин көтүче бүген.
Әткәм чыбыркысы <....> минем кулда! (*Л. Гыйбадуллинадан*)

3. *Әткәм чыбыркысы* <-> *минем кулда!* җөмләсендә <....> тамгасы урынына куелырга тиешле тыныш билгесен языгыз. **(2 балл)**
**сызык**
4. Шигырьдән аваз ияртемнәреннән ясалган сүзләрне күчереп языгыз, сүз төркемен һәм төркемчәсен билгеләгез. (**3 балл**)
**шартлый – хәзерге заман хикәя фигыль, ыслап, чыелдатып – 1 төр хәл фигыль**
5. Беренче дүртьюллыктан тартымлы исемнәрне күчереп языгыз, мәгънәле кисәкләргә аерыгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ ясагыз. (**5 балл**)
Аягың: аяк – тамыр, -ың – бәйләгеч кушымча. Аягың – тамыр, уртаклык исем, баш килештә, 2 зат берлектәге тартым белән төрләнгән.
Чыбыркыңны: чыбыркы – тамыр, -ың – бәйләгеч кушымча, -ны – бәйләгеч кушымча. Чыбыркыңны – тамыр, уртаклык исем,төшем килешендә, 2 зат берлектәге тартым белән төрләнгән.
Кулыңа: кул – тамыр, -ың – бәйләгеч, -а бәйләгеч кушымча. Кулыңа - тамыр, уртаклык исем, юнәлеш килешендә, 2 зат берлектәге тартым белән төрләнгән.
Хәтеренә: хәтер – тамыр, -е -бәйләгеч, -нә – бәйләгеч кушымча. Хәтеренә - тамыр, уртаклык исем, юнәлеш килешендә, 3 зат берлектәге тартым белән төрләнгән.
6. *Галәм хәтеренә аваз киртләп* җөмләсендәге *киртләп* сүзен ничек аңлыйсыз? Үз сүзләрегез белән аңлатып языгыз. (**3 балл**)
**киртләп – искәртеп, хәтергә төшереп, кисәтеп**
7. *Елан төсле ыслап,Чыелдатып шартлый чыбыркым ла.* җөмләсенә синтаксик анализ ясагыз. **(5 балл)**
Бу – ике составлы җәенке, тулы хикәя җөмлә. Чыбыркым – ия, шартлый – хәбәр, елан төсле (ыслап) – рәвеш хәле; ыслап, чыелдатып –тиңдәш рәвеш хәлләре.
8.“*Авылым хәтирәләре*” темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)